**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

10.07.2017 № 436

**Социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирү турында**

«Локомотив ярымутравы районында Яхт-клуб» спорт объектын урнаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{6}$ статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясы нигезендә:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан 2800 квадрат метр мәйдандагы 16:50:012005:1 кадастр номерлы, 7528 квадрат метр мәйдандагы 16:50:000000:21202 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен сәүдә уздырмыйча Казан «Органик синтез» гавами акционер җәмгыятенә бирергә һәм әлеге юридик зат белән җир турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә аренда шартнамәсе төзергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**